**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 1 апрель

№ 201

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлар җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлар җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 13 апрель, 257 нче; 2011 ел, 21 декабрь, 1051 нче; 2012 ел, 9 февраль, 95 нче; 2012 ел, 29 май, 436 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 758 нче; 2012 ел, 3 ноябрь, 940 нчы; 2013 ел, 16 октябрь, 763 нче һәм 2014 ел, 7 март, 145 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлар җәмгыятьләре исемлегендә:

2, 3 нче пунктларны төшереп калдырырга;

Акцияләренең дәүләт пакетлары «Связьинвестнефтехим» ачык акционерлар җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң «Связьинвестнефтехим» ачык акционерлар җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлар җәмгыятьләре исемлегендә:

8 нче пунктны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 20 нче пункт өстәргә:

«20. «Казан» халыкара аэропорты» ачык акционерлар җәмгыяте.»;

Акцияләренең дәүләт пакетлары «Ак Барс» холдинг компаниясе» ачык

акционерлар җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң «Ак Барс» холдинг компаниясе» ачык акционерлар җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлар җәмгыятьләре исемлегендә:

4 нче пунктны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\201.doc